КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 30 март г.Казань № 304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 20 февраль, 99 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, журналистика өлкәсендә иҗади хезмәткәрләрнең кадрлар потенциалын ныгыту чараларын оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләре, дәүләт корпорацияләре (компанияләре) һәм гавами-хокукый компанияләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 20 февраль, 99 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 29 октябрь, 876 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «төбәкара хезмәттәшлек» сүзләреннән соң «, халыкара театр фестивальләрендә катнашу» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «төбәкара хезмәттәшлек» сүзләреннән соң «, халыкара театр фестивальләрендә катнашу» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чараларны оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, журналистика өлкәсендә иҗади хезмәткәрләрнең кадрлар потенциалын ныгыту чараларын оештыруга һәм уздыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен

дәүләт (муниципаль) учреждениеләре, дәүләт корпорацияләре (компанияләре) һәм гавами-хокукый компанияләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «төбәкара хезмәттәшлек» сүзләреннән соң «, халыкара театр фестивальләрендә катнашу» сүзләрен өстәргә;

1.1 пунктта «шул ук вакытта физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга, «төбәкара хезмәттәшлек» сүзләреннән соң «, халыкара театр фестивальләрендә катнашу» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«иминият шартнамәсен рәсмиләштерү чыгымнары.»;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

1.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидия (С) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = Р_1 + Р_2 + Р_3 + Р_4 + Р_5 + Р_6 + Р_7 + Р_8 + Р_9 + Р_{10},$$

монда:

$Р_1$ – штат хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

$Р_2$ – белгечләрнең хезмәте өчен түләү, шул исәптән граждан-хокукый шартнамәләр нигезендә проектларны һәм чараларны оештыру һәм уздыру, эшләр башкару өчен җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәте өчен түләү;

$Р_3$ – Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

$Р_4$ – салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә салымнар түләү;

$Р_5$ – проектларны һәм чараларны оештыру һәм уздыру, эшләр башкару өчен чыгым материаллары, төп чаралар сатып алу;

$Р_6$ – мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алу чыгымнары;

$Р_7$ – проектларны һәм чараларны оештыру һәм уздыру, эшләр башкару өчен бүлмәләрне, җайланмаларны, җиһазларны, костюмнарны, музыка уен коралларын арендалау;

$Р_8$ – элемтә, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәт күрсәтүләр, мөлкәтне карап тоту хезмәтләре, мөлкәтне саклау хезмәтләре, иминият хезмәтләре, аудио- һәм видеоязмалар хезмәтләре, компакт-дисклар төзү буенча хезмәтләр, аудио- һәм видеороликлар, чаралар үткәрү урынын рәсмиләштерү хезмәтләре, тавыш белән тәэмин итү, чараларда катнашучыларны тукландыруны оештыру чыгымнары, алга таба сату өчен билгеләнмәгән бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу (әзерләү) чыгымнары, истәлекләр һәм мемориаль такталар булдыруга һәм урнаштыруга чыгымнар;

$P_9$ – яшәү хезмәтләренә чыгымнар – штаттагы хезмәткәрләргә, проектлар һәм чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән белгечләргә торак арендасын түләү;

$P_{10}$ – иминият шартнамәсен рәсмиләштерү чыгымнары.

Бу пунктта күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар Россия Федерациясе законнары нигезендә, шулай ук бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.»;

1.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.13. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

а) проектларны гамәлгә ашыру кысаларында:

заявка нигезендә гамәлгә ашырылган проектлар саны – кимендә бер берәмлек;

фактта җәлеп ителгән максатчан аудитория – кимендә 100 кеше;

б) заявка нигезендә гамәлгә ашырылган чараларны оештыру һәм уздыру кысаларында:

сәнгати-техник параметрларга туры килә торган, гамәлгә ашырылган чаралар саны – кимендә бер чара;

катнашучылар саны – кимендә 100 кеше;

башкаручылар саны – кимендә бер кеше яки бер оешма;

в) эшләр башкару кысаларында:

Татарстан АССРның сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган кимендә бер кешесен эзләү;

Татарстан АССРда туган, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган кимендә бер кешесен эзләү;

в) чараларда катнашу кысаларында:

катнашкан халыкара театр фестивальләре саны - кимендә бер.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

3.3 пунктның икенче абзацында «өч» сүзен «10» саннарына алмаштырырга;

7.7 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.6 пунктның беренче абзацта «Бирелгән субсидия тиеш» сүзләрен «Субсидия акчалары тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

8.7 пунктның беренче абзацында «субсидия» сүзен «субсидия акчалары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин